КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 14 ноябрь г.Казань № 867

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрүгә, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары эшчәнлеген җайга салуга, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторларның инвестиция программаларын раслауга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органын билгеләү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 ел, 24 июнь, ФЗ-89 нчы Федераль закон, Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын түбәндәгеләргә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы итеп билгеләргә:

каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторларын (алга таба – төбәк операторы) конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрүгә, шул исәптән: төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алу турындагы документларны әзерләүгә һәм раслауга, төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алу буенча конкурс комиссиясен формалаштыруга, төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алу процедурасын үткәрүгә, төбәк операторлары белән каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча эшчәнлек оештыру турында килешүләр төзүгә;

төбәк операторлары эшчәнлеген җайга салуга (төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен билгеләүдән тыш);

каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторларның инвестиция программаларынраслауга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2007 ел, 18 май, 196 нчы; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы, 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче; 2015 ел, 1 июнь, 397 нче; 2016 ел, 10 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 13 декабрь, 925 нче; 2017 ел, 6 март, 127 нче; 2017 ел, 26 май, 309 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«төбәк операторлары эшчәнлеген җайга сала (төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен билгеләүдән тыш);

коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алуны оештыра;

каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторларның инвестиция программаларын раслый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\867.docx